2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авылы җирлеге Яңа Нәдер авылында гражданнарның үзара салымын кертү турында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

28 ноябрь 2022 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл җирлегенең Яңа Нәдер авылында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл җирлегенең Яңа Нәдер авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертергәза, моннан тыш, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (ата-аналар, ир белән хатын), күпбалалы гаиләләр һәм 1 төркем инвалидлардан тыш,.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә: су белән тәэмин итү системасын норматив халәткә китерү, су белән тәэмин итү системаларын норматив хәлгә китерү өчен җиһазлар сатып алу; урам утларын һәм юлларны норматив хәлгә китерү, сметалар төзегән өчен түләү, техник күзәтчелек үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Яңа Нәдер авылы, Совет урамы, 81 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Нәдер авыл җирлеге башлыгы С.М. Миннебаев